**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АЙБАШ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422726, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Айбаш авылы, Үзәк ур.,1А

**СОВЕТ АЙБАШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422726, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Айбаш, ул.Центральная, 1А

Тел./факс: +7(84365) 60-7-23, e-mail: Ayb.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**21 июнь 2019 ел** **№ 153**

**Айбаш авыл җирлеге Советының 08.10.2018 № 130 карары белән расланган “Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыены уздыруга әзерлек тәртибе турында” нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында 2019 елның 1 маендагы 87-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлеге советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда Айбаш авыл җирлеге Советының 08.10.2018 № 130 карары белән расланган Гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында” Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.6 пунктның 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“яңа оешкан җирлек булдыру турында халык инициативасын тәкъдим итү максатында, авыл җирлегендә, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр сайлау хокукына ия кешеләр саны 300 кешедән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча;”.

2) 3.5 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Халык җыены, анда торак пунктта яки җирлектә яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булучыларның яртысыннан артыгы катнашында хокуклы. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыграгы берьюлы бергә катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, составына күрсәтелгән торак пункт кергән Айбаш авыл җирлеге Уставы нигезендә гражданнарның җыелышы гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгәннән соң бер айдан да артмаган вакыт эчендә үткәрелә. Шул ук вакытта элегрәк гражданнар җыенында катнашкан затлар алдагы этапларда тавыш бирүдә катнашмыйлар. Гражданнар Җыенының карары гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы аның өчен тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга (халыкка җиткерергә).

3. Бу карар рәсми бастырылганнан соң үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Р.Р. Сафиуллин